РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОГРИШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,
Менделеевский район, Республика
Татарстан, 423642

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 1 йорт,
Иске Гришкино авылы, Менделеевск
районы,
Татарстан Республикасы,423642

Тел. (факс): (85549) 3-51-18
e-mail: Sgr.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03. 2025 ел №11

Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны
билгеләү турында һәм хуҗасыз хайваннарны
элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар
кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге Уставы нигезендә. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы Алексеев Константин Ильичны хуҗасыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Иске Гришкино авылы махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Иске Гришкино авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге Советының
2025 елның 3 мартындагы 11 номерлы
карарына 1 кушымта

Иске Гришкино авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Хайваннарны приютта стерильләштерү , тамгалау, исәпкә алу, карантинлаштыру, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивацияләнмәгән агрессивлык күрсәтми торган хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына ( тотылган ау урынына) кире кайтару тыела, әгәр мондый хайваннарны приютларда, һәм территориядән 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса:

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.
- җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).
- белем бирү оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.
- мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.
- җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектлары урнашкан урыннар.
- йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.
- күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.
- Зиратлар һәм мемориаль зоналар.